СОВЕТ
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ
ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: Mcel.Drz@tatar.ru,

**РЕШЕНИЕ** *с.Малая Цильна* **КАРАР**

2022 елның 3 нче октябре №21/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авылы җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында карарга үзгәрешләр кертү хакында

2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авылы җирлеге Советы карар КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авылы җирлеге Советының 25.10.2019 ел, №49/2 карарына «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авылы җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылуда катнашу турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.13 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.13. нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген белдерә торган документларның дубликатларын бирү.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктын өстәргә:

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авылы җирлеге башкарма комитеты секретаре күрсәтелгән 3 пунктта нотариаль гамәлләр башкарылган очракта нотариаль документларны саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм куллануны тәэмин итә. Җирлек бетерелгән яки муниципаль берәмлек үзгәртеп корылган очракта, бетерелгән яки үзгәртелгән җирле үзидарә органының нотариаль документлары җирле үзидарә органына тапшырыла.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларына, Чүпрәле муниципаль районы рәсми сайтына, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru).

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Ш.Халитов